**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1824**
**14.04.2020**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзелеш белән бәйле булмаган максатлар өчен җир участокларын бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 21 октябрендәге 4693 номерлы карары үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзелеш белән бәйле булмаган максатлар өчен җир участокларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 21 октябрендәге 4693 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга (Челнинские известия, № 207-208, 28.10.2009).

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (htpp://pravo.tatarstan.ru), шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов